СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.12.2025 Баулы шәһәре № 21

Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 149 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторлары, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 149 номерлы карарына (Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 28 сентябрендәге 176 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 274 номерлы, 2021 елның 14 декабрендәге 90 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 138 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 151 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 257 номерлы, 2024 елның 8 ноябрендәге 273 номерлы, 2025

елның 15 маендагы 310 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның 3 абзацында «15 389» саннарын «16 928» саннарына алмаштырырга;

күрсәтелгән карарга 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисадый үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Советының 2018 елның
20 апрелендәге 149 номерлы
карарына
2 нче кушымта

(Баулы муниципаль районы Советының
2025 елның 12 декабрендәге
21 номерлы карары редакциясендә)

Муниципаль район башлыгының, муниципаль район башлыгы урынбасарының һәм муниципаль районның контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфа атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 4 төркем |
| Муниципаль район башлыгы | 47 056 |
| Муниципаль район башлыгы урынбасары | 42 348 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 42 348 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары | 38 086 |
| Контроль-хисап палатасы аудиторы | 30 809 |